**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"29" март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы «2024 елга гражданнарнын узара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. ТР Әтнә МР Олы атна авыл җирлегенең Кече Әтнә торак пунктында гражданнар җыены карарына 19.11.2023 № 2, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1. карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:**

"Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Кече Әтнә торак пункты урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кырку, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан чистарту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); спорт мәйданчыгын төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау(материаллар сатып алу,эш һәм хезмәтләр өчен түләү));

2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү,ремонтлау,тоту (Кече Әтнә авылының урам юлларын ремонтлау һәм япмаларын төзү (материал сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремотлау (зиратны саклау һәм төзекләндерү, үлән кырку, агачларны, куакларны, үсентеләрне кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

**2. карарның 3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:**

"Сез 2023 елга гражданнар җыены белән билгеләгән спорт мәйданчыгын төзү өчен 27 000 сум күләмендә файдаланылмаган гражданнарның үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) спорт мәйданчыгын төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау(материаллар сатып алу,эш һәм хезмәтләр өчен түләү);»

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы — Порфирьев С.Н.